| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.08.2017 Казан ш. № 5-5/тэ

"Казан сөт комбинаты" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгеләү хакында

"Җылы белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең "Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында" 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Казан сөт комбинаты" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) шушы карар кушымтасы нигезендә тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
31.08.2017 № 5-5/тэ карарына кушымта

"Казан сөт комбинаты" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Су | Басым белән сайлап алынган пар | | | | Әче һәм редуцияләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см2 кадәр | югары 13,0 кг/см2 | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | "Казан сөт комбинаты" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр | 1164,65 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр | 1374,29 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге